| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ «СТАРОИШТЕРЯКСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ» ЛЕНИНОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛЕНИНОГОРСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ «ИСКЕ ИШТИРӘК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

03 август 2021 ел № 15

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Иске Иштирәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты карарының үз көчен югалтуын тану турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2010 елның 2 ноябрендәге 880 номерлы карарына таянып, Лениногорск муниципаль районы «Иске Иштирәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1.Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Иске Иштирәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының «Адресларны бирү, үзгәртү һәм юкка чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2018 елның 31 июлендәге 4 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

2.Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Иске Иштирәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының «Адресларны бирү, үзгәртү һәм юкка чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2020 елның 19 ноябрендәге 12 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Иске Иштирәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы “Иске Иштирәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең административ регламентларын раслау турында» 2019 елның 29 октябрендәге 28 номерлы карарының 1 пукнтының 4 абзацы үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карарны Иске Иштирәк авыл җирлеге буенча урнашкан мәгълүмат стендларында, Лениногорск муниципаль районының рәсми Интернет-сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплыгымда калдырам.

«Иске Иштирәк авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы А.А.Вәлиәхмәтов